ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 112 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 23 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1998 елның 30 октябрендәге 1840 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 7 – 8; 2003, № 10; 2006, № 2 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 12 (I өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле өченче өлеш өстәргә:
«3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вазыйфага сайланган көненнән алып бер айдан да соңга калмыйча ант итә.»;

2) 112 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясына, отставкадагы Татарстан Республикасы Конституция суды судьясына таныклык бирелә. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы һәм отставкадагы Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы таныклыкларын бирү тәртибе турында нигезләмә һәм аларның тасвирламасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның

17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), № 11 (II өлеш); 2014, № 6, (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 пунктындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Җәмәгать судьяларының вәкаләтләре, эшчәнлек тәртибе һәм җәмәгать судьялары вазыйфаларын булдыру тәртибе Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясе суд системасы турында» 1996 елның 31 декабрендәге 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон, башка федераль конституциячел законнар, «Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары турында» 1998 елның 17 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары турында» Федераль закон), башка федераль законнар белән билгеләнә, ә җәмәгать судьяларын сайлау һәм аларның эшчәнлек тәртибе шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон белән билгеләнә.»;

2) 2 статьяда «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законында» сүзләрен «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы Россия Федерациясе Законында (алга таба – «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законы)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 4 статьяның $5^1$ пунктында «һәм дәгъва гаризаларының» сүзләрен «, дәгъва гаризаларының һәм мәҗбүри түләүләрне түләттерү хакындагы таләпләр һәм санкцияләр таләпләре буенча суд боерыгын чыгару турында гаризаларның» сүзләренә алмаштырырга;

4) 8 статьяда:

а) $1^1$ пунктның 3 пунктчасында «квалификация» сүзен «Квалификация» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «квалификация» сүзен «Квалификация» сүзенә алмаштырырга;

5) $10^1$ статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җәмәгать судьясына, отставкадагы җәмәгать судьясына таныклык бирелә. Җәмәгать судьясы һәм отставкадагы җәмәгать судьясы таныклыкларын бирү тәртибе турында нигезләмә һәм аларның тасвирламасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 16 ноябрь
№ 80-ТРЗ